| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НОВОБИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.08.2025 Яңа Авыл авылы № 12

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетының 02.09 2021 елда кабул иткән 14нче номерлы «Агачларны, куакларны газонны кисү, формалаштыру һәм күчереп утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге территориясендәге Россия Федерациясе дәүләти урман фондына һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында"гы 2021 елның 12 февралендә кабул ителгән 8-1 номерлы карарын исәпкә алып, Әгерҗе районы прокуратурасының 11.03.2025 02-08-01-2025/Прдп110-25-20920003/54 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетының «Агачларны, куакларны, газонны формалаштыруга, сүтүгә һәм күчереп утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 02.09.2021 кабул ителгән 14нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.5.2.1 пунктының 7 абзацын, 3.5.2.2 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел үсентеләрнең һәм компенсацион яшелләндерү бәясен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетының 25.08.2025 кабул ителгән 11нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа

Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел үсентеләрнең бәясен исәпләү методикасы нигезендә исәпләп чыгара”

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында Әгерҗе муниципаль районының официаль сайтында https://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәренә урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе Т. С. Николаева